**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25 март 2024 ел** **№2**

**Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу торак пунктында авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 06 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе, нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 05.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 11 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: ТР, Биектау районы, Ташсу авылы, Гагарин урамы, 10 нчы йорт каршында.

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- урам яктыртычны ремонтлау;
- тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы);
- санкцияләнмәгән чүплекне бетерү;
- спорт мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү.)

2023 елның 30 октябрендәге 4 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләргә үзгәртү:

- урам яктырткычны ремонлау (урам утларын ремонтлау)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы))

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (санкцияләнмәгән чүплекне бетерү)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (спорт мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев